

Бу халыкара конкурс-фестиваль ел саен Россиянен, шул исәптән Мордовиянен дә, торле почмакларында үтә. «Осталар шәһәре» конкурсы Мордовиянен һәрбер районында мәктәп һәм район турлары үтте; республика турын котәбез.
Һонәр сайлау-язмыш сайлау, диләр. Балачак, мәктәп еллары сизелми дә үтеп китә. Ә алда, мәктәпне тәмамлагач, зур тормыш юлы котә. Шуна мәктәптә ук профориентация буенча зур эш алып барыла. Һонәр сайлау - кеше тормышында ин әһәмиятле мәсьәләләрнен берсе, дидек. Заман үзгәрә барган саен, тормыш яна һонәрләр таләп итә. Гомерлек юлны сайлау бик авыр. Ярдәмгә торле конкурслар да килә. Шулай, Рузаевка шәһәре «Юнитэр» дигән остәмә белем бирү Үзәгендә «Осталар шәһәре» профориентация чарасынын район этабы үткән. Анда шәһәр һәм район мәктәпләре ярышларында жинеп чыккан 150ләп укучы жыелган. «Осталар шәһәре» - киләчәк профессиянне сайлау юлында беренче адым. Һәм бу адымнар унышлы булуы моһим. Командалар унар укучыдан торды һәм алар сайлаган профессияләре буенча туплаган белемнәрен билгеләнгән тукталышларда урын алып күрсәттеләр. Мәсәлән, «Тәмнәр Империясе» станциясен Р. Абаева, В. Артюшкина, П. Екатеринина шәхси эшмәкәрләренен икмәк пешерү Йортлары кондитерлары һәм кафе «Буше» (ИП Жалилова) поварлары житәкчелегендә яшь кулинарлар һәм аш-су бизәүчеләр (карвинг) осталары кочләрен сынаганнар. Тагы бер станция - «Чибәрлек технологиясе». Парикмахерлар-чәчтарашлар, маникюр студиясе, әйберләрне бисер һәм декоратив янарту буенча да берничә эшкә алучы (работодатель) белән оештырылган. Яшьләрне матур прическалар ясый белү бик тә кызыксындырган, чонки кызлар һәм малайлар һәрвакыт матур булырга телиләр. «Шифаханә» тукталышында киләчәк шәфкать туташлары, докторлар жыелган. Анда беренче ярдәм күрсәтү буенча теорияне белү һәм практикада күрсәтү буенча ярышта катнашучыларнын осталыкларын Рузаевка шифаханәсенен олкән шәфкать туташы С.И. Бузакова бәяләгән.
Егетләр очен кон таләп иткән тукталышлар - «Строймастер», «Сервис үзәге» һәм башкалар була. Рузаевканын атаклы агач остасы А.С. Жбанов «Агачтан бизәк» тукталышы эшләрен бәяләгән. Биредә дә күбесе малайлар ярышты. Һәрхәлдә, сәләтле мәктәп журналистларын «Рузаевская газета» пресс-үзәге хезмәткәрләре житәкчелегендә мәкаләләре белән бергә интервью ала белүләрен дә күрсәттеләр.
«Юнитэр» белгечләре робототехника буенча мастер-класс күрсәтү оештырганнар. Тугызынчы мәктәп бию коллективы кечкенә күнел ачу концерты да үткәргән. «Осталар

шәһәре» дигән профориентация чарасынын нәтижәләр буенча жинvчеләре - Красносельцо мәктәбе командасы. Кубок һәм дипломнар яулаган команда республика ярышында катначаклар.
Ә «Краснослободск кvпрофильле лицей»ында  алты станция буенча ярышлар vткән: «Агроном мәктәбе», «Ветеринария», «Сервис vзәге» (авыл хужалыгын автоматизацияләv һәм электрификацияләv), «Автомәктәп», «Хәрби хезмәткәр», «Профессиянне тап». Шулай итеп һәрбер районда vзенчәлекле, шул жиргә хас профессия белән бәйле конкурслар да vткән. К.Д.Ушинский да болай ди: “Хезмәт - доньяда бары тик кешегә генә хас һәм бары тик ул гына лаек булган бәхет ул”. Барлык чаралар киләчәк буын вәкилләрен бәхетле итv очен башкарылган.

**Наилә Насырова**